барганнармы?! Әхлакның алар ни икәнен дә белмиләр, ата-анасын, туганнарын оятка калдыралар, авыруга сабыштыралар.

Мәхәббәт өлкәсендә дә әхлак дигән нәрсә бар. Кияүгә чыкмыйча гына бала алып кайткан яшь «аналар», тәннәрен сатып йөрүче егет-кызлар татар яшьләренә хас булган сабырлык, тыйнаклык, әдәплелек сыйфатларын кая куйганнар? Замана чирләре СПИД, наркомания, сифилис кебек чирләрдән курыкмыйлармы? Чәчәктәй гомереңне шундый чирләр һәм иртә килгән үлем белән чагыштырасыңмы? Кеше гомере болай да кыска. Ходай Тәгалә тарафыннан бирелгән гомереңне үзеңнән соң үрнәк эз итеп калдыру бик мәслихәт, ләбаса. Мөхәммәт Мәһдиев язганча, кеше китә – җыры кала.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә: Кытай халкы үз җитешсезлекләрен күрсәтү, тикшерү өчен «Хурлык музее» төзегән. Безгә, татар халкына, бәлки, «Татар милләтенең хаталары», «Әхлак дөньясы» дигән күргәзмә-музейлар кирәктер. Кемнәрдер кабатлаган ялгышны, эшләгән әдәпсезлекне күреп, алдагы буын уйланыр иде. Татар халкы – укымышлы халык бит ул. Музей яшьләрнең үзаңын формалаштыруга ярдәм итәр иде. Яшәүнең нигезе – изгелек.

«Халыкларның сөю һәм алар өчен теләктәш булу, тиешле эш-гамәлләрне кылып, кирәкмәгән эшләрдән тыелып тору, кешеләргә изгелек, яхшылык кылу, ярдәм итү, явызлыкларга изгелек белән каршы булу, сүздән бигрәк гамәл белән яхшылык курсәтү кирәк», – дип язган күренекле мәгърифәтчебез Р.Фәхретдин «Җәвамигүль Кәлим шәрхе» китабында.

Алдан язганнардан чыгып, татар җәмгыятендә түбәндәгеләрне тормышка ашырырга кирәк дигән нәтиҗәгә килдем:

1. Шәхес тәрбияләүгә матур әдәбият һәм телевидение-радионың йогынтысын арттыру.
2. Безнең идеологиягә каршы килә торган чит ил фильмнарын кертмәү.
3. Милли горурлык хисен тәрбияләүдә гаилә белән мәктәпнең хезмәттәшлеген ныгыту.
4. Һәркемгә татарның әхлакый кодексын кулланма итеп алу.

## ИСПОЛЬЗОВАНИЕ ПРОИЗВЕДЕНИЙ ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЫ В РАБОТЕ В ДЕТСКОМ САДУ

**Г.Н. Нигматзянова,**
воспитательница высшей категории
Десткий сад №23 г. Казани (Россия)
E-mail: gulnara03041974@yandex.ru

**Аннотация.** Данная статья раскрывает некоторые особенности работы с дошкольниками по использованию произведений детской художественной литературы. Особое внимание уделяется преемственности между детским садом и школой.

**Ключевые слова:** детский сад, школа, татарский язык, воспитание.
**Summary.** This article is intended for parents of preschoolers to using children's literature to help foster friendly relations in the family. Special attention is paid to the continuity between kindergarten and school.
**Keywords:** kindergarten, school, Tatar language, education.

## МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАРНЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ

Балаларга нәрсә укырга һәм ничек укырга дигән сорау бүген аеруча мөһим. Кеше тормышында китапның өстенлеген күрә белергә, балада китапка хөрмәтне, укучыга карата мөнәсәбәтне мәктәп яшеннән түгел, ә мәктәпкәчә яшьтәге чордан башларга кирәк. Китап уку кешеләрне нинди милләттән, расадан, диннән булуына карамастан бер-берсен аңларга һәм хөрмәт итәргә өйрәтә. Кешелек укымый башласа, ул фикер йөртү сәләтен дә югалта. Шунлыктан тормыш безнең алдыбызга балада китапка карата мәхәббәт тәрбияләүдә балалар бакчасы, гаилә, мәктәпнең бергәләп эшләү бурычын куйды. Балаларны китап укырга өйрәтү тәрбиячеләр һәм әти-әниләр тарафыннан профессиональ әзерлек таләп итә. Димәк, тәрбияче бу очракта әти-әниләр һәм хезмәткәрләр эшен тикшерүче һәм оештыручы рәвешендә генә калмый, ә аларга эшләрендә дөрес юнәлеш бирә. Бу эшне оештыруда программаларның күп булуы ярдәмгә килә. Шуннан чыгып мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләренең педагогик коллективы өлкән тәрбияче җитәкчелегендә программаны сайлап, аңа фәнни методик анализ ясап өйрәнеп кенә калмый, ә һәрбер бүлекнең идеяләрен тормышка ашыру юлларын таба.

Безнең Мәскәү районы 236 нчы балалар бакчасы тәрбия һәм белем бирү эшендә төп программа итеп Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильеваның «Туганнан алып мәктәпкә кадәр» программасын алды. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны әдәбият белән таныштыру эшендә традицион булмаган методларны һәм методик алымнарны кулланабыз. Әлбәттә, яңадан-яңа методик алымнарны куллану балаларны мәктәпкә хәзерләүдә зур әһәмияткә ия. Ә мәктәп сабыйлар өчен серле дөнья, ачылмаган китап. Шуңа күрә аларны мөмкин кадәр күбрәк мәктәп тормышына хәзерләү сорала.

Әлеге катлаулы һәм олы максатны тормышка ашыруда безгә татар һәм рус язучыларының бай мирасы ярдәмгә килә. Без шулар аша балаларны ана теленә өйрәтәбез, тел хәзинәсенең матурлыгын алар күңеленә сеңдерергә тырышабыз.

Балаларны үз ана телендә сөйләшергә, аралашырга өйрәтү туган телебезне ярату, аңа карата ихтирам тәрбияләү бүгенге көндә иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора. Балаларны авазларны дөрес әйтеп, җөмләләрне дөрес төзеп, үзләренең уй-фикерләрен тиешле эзлеклелектә, ашыкмыйча сөйли белүләренә ирешү өчен, сөйләм үстерү юнәлешендә эш алып

барырга тиеш. Ә бу максатларны тормышка ашыруда нәфис сүз, әдәби әсәрләр һәм халык авыз иҗаты әсәрләренең әһәмияте бик зур. Әдәби әсәр балаларның логик фикер сәлатләрен үстерә, дөньяны танып белергә өйрәтә. Матур әдәбият әсәрләре балаларны әһлакый һәм эстетик яктан тәрбияләргә дә ярдәм итә. Балаларны матур әдәбият белән таныштыруда Ф.Ю.Юсупов, З.Ф.Камалова, Р.Г.Борһанованың «Гөлбакча», К.В.Закирова «Иң матур сүз», М.Ф.Кашапованың «Иң татлы тел-туган тел», К.В.Вәлиеваның «Балачак аланы» һәм башка бик күп хрестоматияләрне үз эшебездә кулланабыз.

Безнең балалар бакчасы 34 нче номерлы мәктәп белән берлектә эшли. Башлангыч мәктәп белән берлектә үткәрелгән педагогик киңәшмәдә педагогик коллектив түбәндәге еллык бурычны алды: мәктәпкәчә яшьтәге балаларны әдәбият белән таныштыруда балалар бакчасы, гаилә, мәктәп арасында дәвамчанлыкны булдырырга. Бу максатны тормышка ашыру йөзеннән, балалар бакчасы тәрбиячеләре башлангыч сыйныф укытучылары белем эшчәнлегенә, ә укытучылар тәрбиячеләрнең белем эшчәнлегенә үзара йөрештеләр. Бу үзара йөрешүләр башлангыч мәктәп һәм балалар бакчасы программалары белән тирәнрәк танышуга ярдәм итте.

Безнең балалар бакчасы ел саен 34 нче мәктәп белән берлектә «Тукай кичәләре» үткәрә. Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары һәм 1 нче сыйныф укучылары арасында «Яшь артист» дигән темага шигырь кичәләре оештырыла. Шулай ук М.Җәлил, А.Пушкин, А.Алиш туган көннәре билгеләп үтелә. Быел да Муса Җәлил һәм Г.Тукай туган көннәрен 34 нче мәктәп белән берлектә үткәрергә уйлыйбыз. Безнең балалар бакчасында «Театр сөючеләр» түгәрәге берничә ел рәттән эшләп килә. Татар халык әкияте «Өч кыз», А.Алишның «Куян кызы», рус халык әкиятләре «Шалкан», «Теремкәй» һ.б уйнап күрсәттек.

Әти-әниләр белән эш шәхси әңгәмәләр, консультацияләр, лекторийлар һәм мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләрендә үткәрелгән кичәләрдә катнашу формасында булырга мөмкин.

Балаларда матур әдәбиятка, китаплар укуга кызыксыну тәрбияләүдә гаиләнең дә роле зур. Ләкин бу эшкә дөрес юнәлеш бирергә кирәк. Шунлыктан әти-әниләрнең балалар әдәбияты турында күзаллауларын киңәйтергә кирәк. Һәрбер төркемдә әти-әниләр өчен «Говорим по-татарски. Татарча сөйләшәбез», «Туган телдә сөйләшәбез» стендларын булдырдык. Балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, «Сез моны белергә тиеш», «Бала белән бергә укыйбыз», «Моны белү файдалы», «Бергәләп өйрәник» темаларына стендлар җиһазландырылды. Шул өлкәдә анкеталарга җаваплар алына. Балага әдәби әсәрне кычкырып уку (мәсәлән, йокы алдыннан) пропагандалана. Кварталга бер тапкыр балалар һәм әти-әниләр арасында укылган әдәби әсәрләр, татарча караган мультфильмнар буенча рәсем конкурслары оештырыла. Шулай ук әти-әниләргә телетапшырулар карарга киңәш бирелә. Балалар бакчасында төрле очрашулар, кичәләр еш үткәрелә. Күптән түгел «Салават күпере – бездә кунакта» дигән бик күңелле очрашу булды. Балаларга редакция хезмәткәрләре

«Шалай мажаралары»дигән курчак театры күрсәттеләр. Шулай ук балалар язучылары Эльмира Шәрифуллина, Роберт Миңнуллин белән «Балаларга күчтәнәч»дигән темага очрашулар булды. Балалар һәм тәрбиячеләр алар иҗат иткән шигырьләрне укыдылар, җырлар җырладылар. Муса Җәлилнең туган көне уңаеннан «Муса Җәлил батырлыгы – үлемсез» дигән кичә үткәрергә җыенабыз. Шулай ук балалар, әти-әниләр, тәрбиячеләр белән берлектә Г.Тукайның 130 еллыгын билгеләп үтәргә әзерләнәбез.

Балаларга китап уку, матур әбәбият белән таныштыру аларның акыл эшчәнлеген үстерә, зиһенен камилләштерә. Билгеле булганча, сабыйлар әйләнәтирә дөньяны конкрет күзаллау юлы белән кабул итәләр. Аларга барысы да яңа, кызык тоела. Шигырләрдәге, хикәя һәм экиятләрдәге геройларның образларын, вакыйгаларын, сурәтләүләрне алар күз алдына конкрет китерәләр һәм үзләрен шул вакыйгалар эчендә итеп хис итәләр, хыялланалар. Ләкин нәниләр дә зурлар кебек үк үзләренең тормыш тәҗрибәләренә таянып фикер йөртергә өйрәнә.

Балалар бакчасы, гаилә, мәктәп бергәләп балаларны матур әдәбият белән таныштырып, аларны олы, катлаулы һәм гаять кызыклы дөньяга алып керүдә, аны танып белү серләрен өйрәтүдә ярдәм итәр дип ышанасы килә.

## ТАЛГАТ МИНЛЕБАЕВ – ПЕРЕВОДЧИК

**И.М. Низамов,**
доктор филологических наук, профессор
Казанский (Приволжский) федеральный университет (Россия)
E-mail: nizamil@yandex.ru

**Аннотация.** В данной статье автор рассматривает особенности переводческой работы в журналистике. В связи с этим анализируется работа кафедр журналистики и татарской журналистики Казанского университета и ее представителей. Особенное внимание уделяется деятельности Т.Миннибаева и Ф.Агзамова.

**Ключевые слова:** перевод, двуязычие, теория и практика перевода.

**Summary.** The author considers the peculiarities of translation work in journalism. Consequently he analyzes the work of the departments of journalism and Tatar journalism of Kazan University and their representatives. Particular attention is paid to the work of T.Minnibaev, F.Agzamov.

**Keywords:** translation , bilingualism , the theory and practice of translation.

## ТӘЛГАТ МИҢЛЕБАЕВ – ТӘРҖЕМӘЧЕ

Күренекле журналист-публицист, мөгаллим, җәмәгать эшлеклесе, фән кандидаты, тик арабыздан бик яшьли киткән (10.01.1953 – 16.08. 1991) Тәлгат